**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 22 ноябрендәге 4752 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 8646 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:170972:13, 16:50:170974:7, 16:50:170960:26, 16:50:170972:4, 16:50:170964:36, 16:50:170975:5, 16:50:170964:85, 16:50:000000:17900, 16:50:170974:6, 16:50:170972:5, 16:50:170972:3;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары: 16:50:170972, 16:50:170974, 16:50:170964, 16:50:170960, 16:50:170975, 16:50:000000;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 2 ел;

1.2. гариза бирүче: «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең гаризасы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. Әлеге карарның 1 һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1 номерлы, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 22 ноябрендәге
4752 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Идел буе районында**
**ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб 1:2000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |

| | |
|---|---|
| | кызыл линияләр |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:170972, 16:50:170974, 16:50:170964, 16:50:170960, 16:50:170975, 16:50:000000. | кадастр кварталы |
| 16:50:170972:13, 16:50:170974:7, 16:50:170960:26, 16:50:170972:4, 16:50:170964:36, 16:50:170975:5, 16:50:170964:85, 16:50:000000:17900, 16:50:170974:6, 16:50:170972:5, 16:50:170972:3. | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________________